**дөнья бу...**

**Коммунизм төзергә күпме тырышсак та, булдыра алмадык. Максатыбызга ирешсәк, ничек рәхәт яшәр идек. Ачлангачлар, сукбайлар булмас иде. Кешеләр бер-берсенә яхшылык кына эшләр иде. Черегән байлар да, хәерчеләр дә булмас иде. Ил байлыгы да, эш хакы да тигез бүленер иде. Беренче карашка, бу фикерләр романтика сыман тоела. Мондый тормыш оҗмахта гына очрыйдыр. Баксаң, XXI гасырда да коммунизм кануннары буенча яшәүчеләр бар икән. Израильдә кибуцлар — авыл хуҗалыгы коммуналары сакланып калган. Башкортстан дәүләт аграр университеты укытучысы Тамара Вострецова “Шфаим” кибуцында булып, бик куп күренешләргә гаҗәпләнеп кайткан.**

# Кибуцларда гөлләр чәчәк ата

## Израильдә стажировка уткән якташыбыз Тамара Вострецова коммунизм “оҗмах”ына юлыккан

— БДАУның бер теркем укытучылары Израильгә стажировка үтәргә барды, — ди ул. — Без “Шфаим” кибуцында яшәдек. Таныш булмаган сүзгә ачыклык кертергә кирәктер. Берниче гаилә бер кибуцка берләшә. Мондый торак пунктта йездән ике меңгә кадәр кеше яши. Һәркем үзенең эш хакын “уртак казан”га сала. Шуннан соң акча һәркемгә бүленә. Элегрәк кибуцлар башлыча авыл хуҗалыгына махсуслашкан. Хәзер бетен тармак та үстерелә. Әйтик, “Шфаим”да банан, җир җиләге, виноград үстерелә. 1200 баш сыер малы асралучы терлекчелек фермасында булдык. Һәр сыер елына 11 мең килограмм сет бирә. Өчдурт ел саен сыерлар яшь таналарга алыштырыла. Фермада кул көче бетенләй кулланылмый дияргә мемкин. 1200 баш малны нибары җиде кеше тәрбияли. Шәпме? Шәп! Ни дисәң дә, чүлдә мондый казанышларга ирешүче авыл хуҗалыгы игътибарга лаек. Шуны да күздә тотарга кирәк, Израиль аграрийлары Кенбатыш Европа илләрен ел дәвамында яңа елгергән яшелчә-җимеш белән тәэмин итә. Урындагы халык та башлыча үзләрендә җитештерелгән азык-телек белән туклана. Сер түгел, кырыс табигать шартларында мондый максатка заман технологияләренә таянганда гына ирешергә мемкин.

Беренче кибуц 1910 елда Тивериад күле буенда оештырылган. Израиль дәүләте оешкан чорда кибуцлар саны 267гә җиткән. Мондый яшәү рәвешен беркем дә махсус уйлап чыгармаган. Табигать шартлары шуны таләп иткән. Уйлап карагыз, чүлгә аяк баскан ялгыз яһүд тормыш башлый алыр идеме? Кечләрне туплау таләп ителгән. Нәтиҗәдә бер-бер артлы кибуцлар оешкан. Бүген кибуцларда Израильнең 40 процент авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерелә. Җырларда **җырланган оҗмах** почмагында халык нинди шартларда яши?

— Бездә хәлле кешеләр кыйммәтле тунга теренеп, ике миллион сумлык иномаркаларда җилдерә. “Шфаим”да бер атна яшәдем, ярлыларны да, байларны да очратмадым. Беркем дә дәрәҗәсе, кесә калынлыгы белән мактанмый. Һәммәсе дә гади киенә, борын чейми, һәркем белән ихлас исәнләшә. Җитәкчеме, эшчеме, ташчымы, терлекчеме... Җәмгыятьтә һәммәсе дә бертигез. Бу җәһәттән безгә уйланырга урын бар. Гадәттә, кибуцларда гаиләләр бер-ике катлы йортларда яши. Фатирлар зур түгел. Шулай да анда яшәү ечен бетен шартлар да тудырылган. Яшь гаиләләр мондый форсаттан бик теләп файдалана. Башкортстанның кайсы шәһәрендә, район үзәгендә яшь гаиләләргә түләүсез еч бүлмәле фатир бирәләр? Кибуцлар яшь гаиләләргә тормыш башларга, аякка басарга мемкинлек тудыра. Заманча спорт корылмалары, мәдәният үзәкләре, гел-бакчага күмелгән парклар, бассейннар да бар. Керне кер юу урынына илтеп биреп, барып аласы гына. Шундый уңайлы яшәү шартлары тудырылса да, заман үзенекен итә. Израильдә егетләр дә, кызлар да армиягә бара. Хезмәт иткән яшьләрнең 40 проценты гына туган кибуцларына кире әйләнеп кайта. Калганнар бәхетен зур шәһәрләрдә эзли. Шулай булса да, кибуцларның әһәмияте кимеми.

Кибуцлар безнең колхозларны хәтерләтә. Икесенең дә охшаш һәм аермалы яклары бар. Аларны санап китү меһим түгел. Туксан ел элек оештырылган кибуцлар заманга яраклашып, үз йезен, үз традицияләрен саклап калган. Колхозлар күптән таралып бетте. Сынауларга бирешмәгәннәре бармак белән генә санарлык. Фермер хуҗалыкларының хәле дә мактанырлык түгел. Табигать шартлары шактый аерылса да, Башкортстан аграрийларына Израиль тәҗрибәсенә игътибар итү кирәктер. Югары технологияләрне, токымлы малларны чит илдән кайтарабыз. Белгечләр дә җитәрлек. Бетен шартлар тудырылса да, республикада авыл хуҗалыгы һаман үсеш алмый. Ченки җиргә, хезмәткә, кешеләргә хермәт аксый. Хаталар естендә әшне шушы юнәлештә башларга кирәктер.



Тамара Вострецова Иерусалимда Әл-Әкса мәчете каршындагы мәйданда.

**Айдар ЗӘКИЕВ**

реклама